**Яһудин, М. Чалгы чыңы. – Текст: турыдан-туры, электрон / М. Яһудин // Мәйдан. – 2020. – № 2(219). – Б. 97-106. URL: http://maydan.tatar/chalgy-chyny/**




Елга буендагы бу ялгыз йортның тирә-ягын кычыткан, алабута, әремдер кебек чүп үләннәр басып киткән. Абзар, мунча, койма шикелле корылмаларның эзе дә юк. Бүрәнәләре кара көйгән, түбәсе урта бер җирдән сыгылып төшкән әлеге өй, бик теләсә дә билен турайта алмаган картка охшап, мескен бер кыяфәттә бөкрәеп тора иде.

Дөньяның дүрт ягы да ачык булуга карамастан, бу йортның янына килергә шикләнәсең. Урамнан үтеп барышлый, аның пәрәвез каплаган тәрәзәләренә карамаска тырышасың. Ул тәрәзәләр артында кемдер бар, һәм ул сине яшерен генә күзәтәдер кебек.

Караңгы төшеп килә иде инде. Авыл аша бер мосафир узып бара. Теге өйнең морҗасыннан төтен чыгуын күреп, гаҗәпкә калды.

– Әйе, кеше яши анда, – диде, аның соравына капка төбендә утыручы карт. – Тик егерме ел инде күргәнебез юк үзен. Читтә йөреп кайтканнан соң кереп бикләнгән иде… Башта аңламадык, аннары көлдек, шуннан инде, акылга сайдыр дип, кул селтәдек… Айлы төннәрдә күреп калучылар булгалый аны…

Бу өзек Яр Чаллыда яшәп иҗат итүче Марс Яһудинның «Чалгы чыңы» дип исемләнгән яңа хикәсеннән алынды. Әсәр кызыксыну уяткан булса, дәвамын «Мәйдан» журналының быелгы 2нче санында укый аласыз. Шулай ук хикәя белән Интернет челтәрендә **http://maydan.tatar/chalgy-chyny/** сылтамасы аша кереп таныша аласыз.